**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

*2020 елның 20 марты* *135№*

Әлки муниципаль районы Башкарма комититетының 2020 елның 10 февралендәге «Әлки муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламент»ын раслау турында»гы 46 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 8 апрелендәге «Мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча укуга кабул итү тәртибен раслау турында» гы 293 номерлы боерыгы, шулай ук Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2019 елның 30 маендагы «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турында» ТС -1334/13 номерлы хатына карата, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның от 21 февралендәге «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм аларны кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентының якынча формасына үзгәрешләр кертү турында» -269/20 номерлы боерыгы нигезендәге боерыгы белән Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 февралендәге «Әлки муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламент»ын раслау турында"гы 46 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 пунктның 15 абзацын төшереп калдырырга;

16,17 абзацларын 15,16 абзацлар дип санарга;

1.2 пунктның 13 абзацында «наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешмаларны чираттагы уку елына туплау чираттагы уку елына төркемнәр һәм аларда буш урыннар расланган саны нигезендә гамәлгә ашырыла. Буш

урыннар булса, белем бирү оешмасына кабул итү календарь ел дәвамында гамәлгә ашырыла.»;

2 графаның 2.8 пунктындагы «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» таблицсының II кисәгендә «- теләгән Оешмада тәрбия һәм белем алуның теләнгән телгә туры килмәве» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //http:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов

үтәүче: Билалова Г. Ш.
тел. 8(84346)21452